МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.02.2020 г. Казань № 119 од

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1015 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2013 елның 11 ноябрендәге 934 од номерлы, 2015 елның 28 августындагы 941 од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган) расланган Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

**Министр** **И.Х. Әюпова**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1015 од номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2020 елның 21 февралендәге 119 од номерлы боерыгы редакциясендә) расланган

**Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә иң яхшы хезмәткәрләргә һәм учреждениеләргә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын гамәлгә кую тәртибе турында» 2008 елның 21 ноябрендәге 826 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә югары һөнәри осталык һәм тармакны үстерүгә зур өлеш керткән өчен грант рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә (алга таба – мәдәният хезмәткәрләре) ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын (алга таба – грантлар) конкурс нигезендә ел саен бирүнең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

грантлар – субсидияләр рәвешендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чаралары;

грант бирүче – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы – Грантлар бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

гариза бирүче – Татарстан Республикасы мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениесенең коллегиаль органы;

Грантка дәгъва кылучы – мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан

Республикасы Хөкүмәте грантын алуга гаризада (алга таба – Гариза) күрсәтелгән һәм әлеге Нигезләмәнең 1.5 пунктына туры килгән мәдәният хезмәткәре;

проект – мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри үсешенә һәм квалификацияләрен күтәрүгә юнәлдерелгән мәдәни белем бирү чаралары комплексы;

конкурс – Грантларга дәгъва кылучыларны конкурс нигезендә сайлап алу белән бәйле чара;

грант алучы – конкурс нәтиҗәләре буенча Грант бирү турында карар кабул ителгән Грантка дәгъва кылучы;

хисап чоры – Грантлар бирелгән елдан соң килүче финанс елы;

агымдагы ел – конкурста катнашуга Гариза бирелгән ел.

1.4. Грантлар бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

1.5. Конкурста катнашырга эш урыннары Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) бюджет һәм автоном мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре, шул исәптән мәдәният өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре, мәдәният өлкәсендә урта һөнәри белем бирү учреждениеләре (алга таба – Учреждениеләр) булган мәдәният хезмәткәрләре хокуклы.

1.6. Грантлар бирү конкурс нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.7. Грантларның гомуми күләме елына 3000 мең сум тәшкил итә, шулардан:

«Иң яхшы җитәкче» номинациясе буенча – һәркайсы 100 мең сум күләмендәге 7 Грант;

«Профессионал» номинациясе буенча – һәркайсы 70 мең сум күләмендәге 14 Грант;

«Таяныч һәм абруй» номинациясе буенча – һәркайсы 50 мең сум күләмендә 18 Грант;

«Перспектива» номинациясе буенча – һәркайсы 30 мең сум күләмендәге 14 Грант.

## 2. ГРАНТ БИРҮ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ

2.1. Грантлар бирүнең максатлары:

эштә югары күрсәткечләргә ирешкән һәм мәдәният тармагын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән югары профессионал мәдәният хезмәткәрләрен ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри үсеше, аларның мәдәният өлкәсендә квалификациясен күтәрү өчен шартлар тудыру;

мәдәният хезмәткәрләре һөнәренең абруен күтәрү.

2.2. Грант бирү шартлары Грантка дәгъва кылучының Гариза бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килүеннән гыйбарәт:

Грантка дәгъва кылучы мәдәният хезмәткәре булып тора;

Грантка дәгъва кылучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт (территория) теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты түгел;

Грантка дәгъва кылучы Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Гариза бирү датасына кадәрге өч ел дәвамында Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акча алучы булмаган;

Грантка дәгъва кылучының Гариза бирү датасына Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрен, кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы юк һәм, әгәр мондый таләп хокукый актта каралган булса, Татарстан Республикасы бюджетына түләү вакыты узган бүтән бурычы булмаган очракта;

Грантка дәгъва кылучының Гариза бирү датасына салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

Грантка дәгъва кылучы хөкем ителмәгән һәм (яки) аңа карата җинаять эзәрлекләве факты юк.

Грантка дәгъва кылучыны грантлар бирүгә гаризаларны сайлап алу конкурсында җиңүче дип тану.

Грант бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүне тикшерүләрне Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга Грант алучының ризалыгы булу шулай ук Грант бирүнең төп шарты булып тора.

## 3. ГРАНТ АЛУГА КОНКУРС ҮТКӘРҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

3.1. Конкурсны үткәрү һәм грант алучыларны билгеләү өчен Вәкаләтле орган Грант алуга дәгъва белдерүче булып тормаган Вәкаләтле орган, мәдәният өлкәсендә иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендәге белгечләр арасыннан булган экспертлардан Иң яхшы мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы

Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы (алга таба – Совет) төзелә, аңа Совет рәисе һәм әгъзалары составында 15 кеше керә.

Вәкаләтле орган Советның оештыру-техник эшчәнлеген координацияләү, утырышларны әзерләү һәм документларын алып бару өчен Вәкаләтле орган хезмәткәрләре арасыннан җаваплы секретарь билгели. Советның җаваплы секретаре Совет составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка катнаша.

3.2. Советның җаваплы секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

Гаризаларны һәм әлеге Нигезләмәнең 3.9 пунктында каралган аңа кушып бирелә торган документларны кабул итеп ала;

Грантларга дәгъва кылучыларның әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында каралган таләпләргә туры килү-килмәвенә тапшырылган документларны тикшерә;

Гаризаларны һәм аларга кушып бирелә торган документларны терки;

Совет утырышында аларны карау өчен материаллар әзерли;

Совет утырышларын оештыра;

Совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.3. Советның персональ составы, конкурсны үткәрү сроклары Вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

3.4. Конкурс дүрт номинация буенча үткәрелә, алар буенча түбәндәге таләпләр куела:

«Иң яхшы җитәкче» – Грантларга дәгъва кылучылар: Учреждениеләр җитәкчеләре арасында;

«Профессионал» – югары һөнәри нәтиҗәләргә ирешкән Грантларга дәгъва кылучылар арасында;

«Таяныч һәм абруй» – мәдәният өлкәсендә кимендә 20 ел эшләгән Грантларга дәгъва кылучылар арасында;

«Перспектива» – 30 яшькә кадәрге Грантларга дәгъва кылучылар арасында, мәдәният өлкәсендә эшләү стажы кимендә 3 ел булырга тиеш.

3.5. Грантларга дәгъва кылучыларны конкурста катнашуга Гариза бирүчеләр тарафыннан тәкъдим итү аларның язма ризалыгы белән башкарыла.

3.6. Һәр номинация буенча бер Учреждениедән Грантка дәгъва кылучы итеп иң күбе берәү тәкъдим ителә ала.

3.7. Әлеге Нигезләмә кысаларында Вәкаләтле орган:

конкурс үткәрүне оештыра;

конкурсны үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, Гаризаларны кабул итә башлау һәм тәгәлләү вакыты, конкурста катнашучыларга карата таләпләр турында белешмәләрне дә кертеп, конкурсны үткәрү турында мәгълүмат бастырып чыгаруны тәэмин итә;

Гаризаларны һәм аларга кушып бирелгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

үз компетенциясе чикләрендә Совет эшчәнлеген оештыру-техник ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Грантлар бирү турында Совет карарын раслый;

грант алучыларга акча күчерү юлы белән Грантлар түләүне гамәлгә ашыра.

3.8. Конкурсны үткәрү турында игълан, конкурсны үткәрү вакыты, урыны һәм тәртибе, Гаризаларны кабул итә башлау һәм төгәлләү вакыты турында белешмәләрне дә кертеп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Вәкаләтле органның рәсми сайтына (http://mincult.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт) конкурсны үткәрү турында боерык чыккан көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көнлек срокта урнаштырыла.

Гаризалар кабул итү конкурс үткәрү турында игълан рәсми сайтка урнаштырылган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 14 көнлек срокта башкарыла.

3.9. Конкурста катнашу өчен Гариза бирүчеләр Вәкаләтле органга түбәндәгеләрне тапшыралар:

Әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча Гаризаны түбәндәге документлар белән бергә:

Гариза беркетелгән хат (кәгазь һәм электрон чыганакларда);

Грантка дәгъва кылучының паспорты күчермәсе (шул исәптән электрон чыганакта);

Грантка дәгъва кылучының белеме турындагы дипломының (квалификацияне күтәрү яки яңадан әзерлек турындагы документны да кертеп) эш урыны буенча таныкланган күчермәсе (кәгазьдә);

Грантка дәгъва кылучының хезмәт кенәгәсенең тиешенчә таныкланган күчермәсе һәм (яисә) Грантка дәгъва кылучының Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

салым исәбенә куелу турында таныклык (ИНН) күчермәсе (шул исәптән электрон чыганакта);

СНИЛС күчермәсе (шул исәптән электрон чыганакта);

Грантка дәгъва кылучының хөкем ителүе (ителмәве) һәм (яки) аңа карата җинаять эзәрлекләве факты булу-булмау турында йә җинаять эзәрлекләве туктатылу турында белешмә;

Грантка дәгъва кылучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмауны раслый торган салым органы белешмәсе;

Учреждениенең коллегиаль органы җыелышы беркетмәсеннән Грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итү турында өземтә (кәгазьдә);

Грантка дәгъва кылучының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча гариза-ризалыгы (кәгазьдә);

Грантка дәгъва кылучының конкурста катнашуга Гариза бирүчеләр тарафыннан тәкъдим ителүенә гариза-ризалыгы;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралганча тутырылган, Гариза бирүче вәкиле тарафыннан имзаланган Грантка дәгъва кылучы эшчәнлеге турында аналитик белешмә (конкурс критерийларын күз алдында тотып) (кәгазьдә);

Грантка дәгъва кылучы һөнәри эшчәнлегенең күрсәтелгән нәтиҗәләрен раслаучы документлар һәм материаллар (фото- һәм видеоматериалларны да кертеп) (электрон чыганакта);

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча проект (кәгазьдә һәм электрон чыганакларда);

әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымтада каралган форма буенча проектны гамәлгә ашыру чыгымнары сметасы (кәгазьдә һәм электрон чыганакларда).

3.10. Грантка дәгъва кылучы бюджетта бирелә торган Грант хисабына түбәндәге чыгымнарны күздә тотарга хокуклы:

Россия Федерациясе чикләрендә укуны һәм (яки) укуның төрле рәвешләрендә (гавами лекцияләр, конференцияләр, мастер-класслар, семинарлар, тренинглар, форумнар, коучинглар, күргәзмәләр) катнашуны түләүгә;

Россия Федерациясе чикләрендә мәдәният өлкәсендә квалификация күтәрүне һәм (яки) яңадан әзерлек узуны түләүгә;

юлда йөрү һәм яшәү өчен түләүне дә кертеп, командировка чыгымнарын түләүгә.

3.11. Проектны гамәлгә ашыру чыгымнары күләме әлеге Нигезләмәнең 1.7 пунктында күрсәтелгән номинацияләр өчен каралган грант суммасыннан артып китсә, барлыкка килгән аерма Грантка дәгъва кылучының яисә Учреждениенең акчалары хисабына түләнә.

3.12. Грантлар бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

квалификация күтәрү, грант алучының һөнәри үсеше;

ким дигәндә өч мәдәният учреждениесендә тәҗрибә алмашу буенча чаралар үткәрү.

3.13. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган әлеге Нигезләмәнең 3.9 пунктында күрсәтелгән документлар турыдан-туры Вәкаләтле органга әлеге Нигезләмәнең 3.8 пункты нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән срокларда тапшырыла.

3.14. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризалар рецензияләнми, кире кайтарылмый һәм билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле органда саклана.

3.15. Конкурста катнашудан баш тарту өчен нигез түбәндәгеләр була:

Грантка дәгъва кылучының әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 3.9 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булу;

Гариза һәм документларның Гаризаларны кабул итү срогы тәмамлану датасыннан соң тапшырылуы.

3.16. Вәкаләтле органга кергән Гариза ул кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

3.17. Вәкаләтле орган, конкурска документлар кабул итү тәмамланган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, документларны Советка тапшыра.

3.18. Совет документларны алган вакыттан 15 эш көне эчендә аларны карый, әлеге Нигезләмәнең 3.22 пунктында каралган рейтингларга нигезләнеп, грант алучылар исемлеген билгели.

3.19. Конкурс буенча сайлап алу критерийлары:

| № т/б | Гаризаларны бәяләү критерийлары | Бәяләү (балларда) |
|---|---|---|
| **1.** | **Грантка дәгъва кылучының эшчәнлеген бәяләү өчен гомуми критерийлар** | |
| 1.1. | Грант алучының соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) конкурсларда һәм проектларда шәхсән катнашуы нәтиҗәлелеге | Муниципаль дәрәҗәдә катнашу – 1 балл;<br>Муниципаль дәрәҗәдә җиңү – 2 балл;<br>Республика дәрәҗәсендә катнашу – 2 балл;<br>Республика дәрәҗәсендә җиңү – 3 балл;<br>Федераль дәрәҗәдә катнашу – 3 балл;<br>Федераль дәрәҗәдә җиңү – 4 балл;<br>Халыкара дәрәҗәдә катнашу – 4 балл;<br>Халыкара дәрәҗәдә җиңү – 5 балл.<br>Бер дәрәҗә яссылыгында катнашу һәм җиңү буенча күрсәткечләр кушылмый. Максималь кушма балл – 14 балл. |

| | | |
|---|---|---|
| 1.2. | Соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) квалификация күтәрү һәм һөнәри яңадан әзерлек | Юк – 0 балл;<br>Квалификация күтәрүнең, һөнәри әзерлекнең бер төре – 5 балл;<br>Квалификация күтәрүнең, һөнәри әзерлекнең берничә төре – 10 балл. |
| 1.3. | Дәүләт бүләкләре (орденнар, медальләр, мактаулы исемнәр) булу | Юк – 0 балл;<br>Республика әһәмиятендәге – 3 балл;<br>Федераль әһәмияттәге – 7 балл.<br>Күрсәткечләр кушыла. |
| 1.4. | Бүләкләр һәм кызыксындыру чаралары (федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәләрдәге, дәүләтнеке булмаган учреждениеләрнең мактау грамоталары, күкрәк билгеләре, рәхмәт хатлары) булу | Җирле үзидарә органнарыныкы һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләрнеке – 2 балл;<br>Региональ дәрәҗәдәге – 3 балл;<br>Федераль дәрәҗәдәге – 6 балл.<br>Күрсәткечләр кушыла. |
| **Гомуми критерийлар буенча барлыгы:** | | **0 - 45 балл** |
| **2.** | **«Иң яхшы җитәкче» номинациясе буенча конкурсның өстәмә критерийлары** | |
| 2.1. | Соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) федераль һәм региональ массакүләм мәгълүмат чараларында Учреждение эшчәнлеген яктырту | Юк – 0 балл;<br>Бер уңай бәяләмә – 3 балл;<br>Икедән алып дүрткә кадәр – 7 балл;<br>Биш һәм аннан да күбрәк – 10 балл. |
| 2.2. | Соңгы<br>2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) иҗади проектларны тормышка ашыруга һәм матди-техник базаны ныгытуга өстәмә финанс чаралары җәлеп итү | Республика бюджеты – 4 балл;<br>Федераль бюджет – 6 балл.<br>Күрсәткечләр кушыла. |
| 2.3. | Учреждениенең Интернет-сайты булу һәм аның даими яңартылуы | Интернет-сайт юк – 0 балл;<br>Интернет-сайт бар – 1 балл;<br>Яңартылу:<br>Ай саеннан сирәгрәк – 2 балл;<br>Ай саен – 5 балл; |

| | | |
|---|---|---|
| | | Атна саен – 7 балл;<br>Көн саен – 10 балл. |
| **Номинация буенча барлыгы:** | | **0 - 30 балл** |
| **3.** | **«Профессионал» номинациясе буенча конкурсның өстәмә критерийлары** | |
| 3.1. | Һөнәргә кагылышлы басмалар, фәнни-тикшеренү һәм иҗади эш тәҗрибәсе (вакытлы матбугатта, массакүләм мәгълүмат чараларында, җыентыкларда һәм башкаларда мәкаләләр), брошюралар һ.б. булу | 1 басма материал – 3 балл;<br>2 һәм аннан күбрәк басма материал – 5 балл;<br>5 һәм аннан күбрәк басма материал – 10 балл. |
| 3.2. | Эш башкарганда заманча технологияләрне, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану | Куллану – 5 балл;<br>Кулланмау – 0 балл. |
| 3.3. | Соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) муниципаль һәм (яки) региональ дәрәҗәдә үз тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату (мастер-класслар, семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, спикер яки жюри сыйфатында) | Муниципаль дәрәҗәдә – 2 балл;<br>Республика дәрәҗәсендә – 3 балл;<br>Федераль дәрәҗәдә – 4 балл;<br>Халыкара дәрәҗәдә – 6 балл.<br>Күрсәткечләр кушыла. |
| **Номинация буенча барлыгы:** | | **0 - 30 балл** |
| **4.** | **«Таяныч һәм абруй» номинациясе буенча конкурсның өстәмә критерийлары** | |
| 4.1. | Остазлык системасы: Учреждениедә тәрбияләнгән укучылар (эшне дәвам итүчеләр) булу | Бар – 5 балл;<br>Юк – 0 балл. |
| 4.2. | Авторлык программалары, методик һәм дидактик эшләнмәләр, тәкъдимнәр, укыту-методик әсбаплар, җыентыклар булу | 1 программа – 3 балл;<br>2 һәм аннан күбрәк программа – 5 балл;<br>5 һәм аннан күбрәк программа – 10 балл. |
| 4.3. | Соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) | Муниципаль дәрәҗәдә – 2 балл;<br>Республика дәрәҗәсендә – 3 балл; |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль һәм (яки) региональ дәрәҗәдә үз тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату (мастер-класслар, семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, спикер яки жюри сыйфатында) | Федераль дәрәҗәдә – 4 балл;<br>Халыкара дәрәҗәдә – 6 балл.<br>Күрсәткечләр кушыла. |
| **Номинация буенча барлыгы:** | | **0 - 30 балл** |
| **5.** | **«Перспектива» номинациясе буенча конкурсның өстәмә критерийлары** | |
| 5.1. | Үз проектларын/идеяләрен эшләү һәм Учреждение эшенә гамәлгә кертү (эшкә урнашкан вакыттан алып) | 1 алып 3 кадәр проект/идея – 10 балл;<br>3 алып 5 кадәр проект/идея – 15 балл;<br>6 алып һәм аннан күбрәк проект/идея – 20 балл. |
| 5.2. | Коллективның иҗтимагый тормышында һәм үткәрелә торган чараларда актив катнашу | Катнашу – 5 балл;<br>Катнашмау – 0 балл. |
| 5.3. | Учреждение җитәкчесеннән уңай бәяләү булу | Бар – 5 балл;<br>Юк – 0 балл. |
| **Номинация буенча барлыгы:** | | **0 - 30 балл** |
| **6.** | **Проектларны бәяләү критерийлары** | |
| 6.1. | Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте | Проект туры килми – 0 балл;<br>Проект туры килә – 5 балл. |
| 6.2. | Проектны тормышка ашыру өчен планлаштырыла торган чыгымнарның нигезләнгән булуы | Планлаштырыла торган чыгымнар проектның куелган максатына ирешүгә һәм бурычларын хәл итүгә ярашлы түгел – 0 балл;<br>Планлаштырыла торган чыгымнар проектның куелган максатына ирешүгә һәм бурычларын хәл итүгә ярашлы булуы тулысынча түгел – 3 балл;<br>Планлаштырыла торган чыгымнар чынбарлыкка туры килә, проект бурычларын хәл итүгә һәм максатларына ирешүгә ярашлы һәм ресурслар тасвирламасына таяна – 5 балл. |
| **Проект буенча барлыгы:** | | **0 - 10 балл** |

3.20. Совет әгъзасы һәр критерий буенча баллар куя. Һәр критерий буенча баллар куелып беткәннән соң баллар кушыла.

3.21. Баллар эксперт кәгазьләренә кертелә, алар Совет әгъзалары тарафыннан ирекле рәвештә тутырыла, Совет әгъзасы имзасы белән раслана һәм Совет рәисенә тапшырыла.

3.22. Әлеге Нигезләмәнең 3.19 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча Совет әгъзалары тарафыннан куелган балларны кушу нәтиҗәләренә карап, Грантларга дәгъва кылучыларның йомгаклау рейтингы төзелә, анда җыелган баллар номинацияләр буенча кими бару тәртибендә күрсәтелә.

3.23. Әлеге Нигезләмәнең 1.7 пункты нигезендә номинацияләр буенча күрсәтелгән рейтингта иң югары урыннарны алган Грантларга дәгъва кылучылар Конкурсның җиңүчеләре дип таныла.

3.24. Совет карары, әгәр аның өчен шунда булган Совет әгъзаларының күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч була.

3.25. Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

3.26. Совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

3.27. Грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

грант алучының Грант бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуына ризалык бирмәве;

Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булу.

3.28. Грантлар бирү турында боерык чыккан көннән алып өч эш көне эчендә рәсми сайтка сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырыла, ул шул исәптән сайлап алуда катнашучылар, рейтинг һәм бирелә торган Грантлар күләме турында мәгълүмат урнаштыруны да күздә тота.

3.29. Грант алучылар турында Вәкаләтле орган боерыгы чыккан көннән алып календарь көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма буенча килешү төзелә.

3.30. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

Грант күләме;

Грант бирү максатлары;

Грант күчерү тәртибе һәм сроклары;

Грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең зурлыгы;

Гранттан файдалану турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы;

Грант күчерүне туктатып тору, туктату өчен нигезләр һәм Грант күләмен киметү һәм кире кайтару тәртибе;

Грантны мәҗбүри кире кайтарттыру буенча чаралар күрү сроклары;

грант алучының Грант бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуына ризалыгы;

килешү шартларын бозган өчен җаваплылык.

## 4. ГРАНТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

4.1. Грантлар грант алучыларның Россия кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына, Грант бирү турында Вәкаләтле орган боерыгына нигезләнеп, Грант бирү турында килешүгә яклар кул куйган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә күчерелә.

4.2. Әгәр җиңүче Грант бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәсә, Вәкаләтле орган конкурста җиңүчеләр белән килешүне өзү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган типлаштырылган форма буенча өстәмә килешү төзи. Башка кирәкле очракларда грант алучы белән килешүгә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган форма буенча төзелә.

## 5. ГРАНТ АЛУЧЫЛАР ТАРАФЫННАН ХИСАП БИРҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ СРОКЛАРЫ

5.1. Грант алучылар Вәкаләтле органга Грант түләүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында һәм хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап тапшыралар.

5.2. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисапта түбәндәге позицияләрне күрсәтү киңәш ителә:

куелган максатларга ирешү;

Грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең килешүдә күрсәтелгән зурлыкларына, проектта күрсәтелгән сыйфат һәм сан нәтиҗәләренә ирешү (Грант буенча үз йөкләмәләренең үтәлешен раслаучы документлар (билгеләнгән тәртиптә таныкланган, укуны уңышлы тәмамлауны һәм (яки) проектта каралган катнашуны раслый торган документлар яки күрсәтелгән документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, аларның күчермәләре), тәҗрибә алмашу чараларын гамәлгә ашыру өчен шартлар биргән оешмаларның вазыйфаи затларының имзалары куелган бәяләмәләр кушып бирелгән тасвирлама хисап, фото- һәм видеоматериаллар).

5.3. Грант түләүгә бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалану турындагы хисап әлеге Нигезләмәнең 3.28 пунктында каралган килешү нигезендә ике нөсхәдә язма рәвештә тапшырыла.

5.4. Хисапка беренчел финанс документлары күчермәләре теркәлә.

5.5. Грант акчаларының хисап елыннан соң килә торган финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган өлеше грант алучы тарафыннан Вәкаләтле органның тиешле таләбе алынган көннән алып 15 эш көне эчендә килешүдә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

5.6. Гранттан максатка ярашсыз файдалану факты ачыклану турында грант алучыга Вәкаләтле орган грант алучының Гранттан максатка ярашсыз файдалануы факты ачыкланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә хәбәр итә.

5.7. Грант алучы тарафыннан Грант Вәкаләтле органның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

грант алучы Грант бирүнең әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә билгеләнгән максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән;

әлеге Нигезләмәнең 3.12 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре ирешелмәгән;

грант алучы Гранттан максатка ярашсыз файдаланган.

грант алучы тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән нигезләр буенча Грантны кире кайтару срогы бозылганда, Вәкаләтле орган Грантны кире кайтару срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән чараларны Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтару буенча чаралар күрә.

5.8. Грант акчаларын Татарстан Республикасы бюджеты керемenә ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында каралган очракларда, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелергә тиеш.

5.9. Грант алучылар тарафыннан Грант бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри тикшерүләр үткәрү юлы белән башкара.

Мәдәнирят, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

(Форма)

# МӘДӘНИЯТ, СӘНГАТЬ ҺӘМ КИНЕМАТОГРАФИЯ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНЕҢ ИҢ ЯХШЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ ГРАНТЫН АЛУГА ГАРИЗА

Грантка дәгъва кылучы катнаша торган номинация ____________________________________________
Грантка дәгъва кылучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булганда)______________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының вазыйфасы, эш урыны____________________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының туган көне __________________________
(көн, ай, ел)
Грантка дәгъва кылучының гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме __________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре (исемен һәм бирелү датасын күрсәтеп)_________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының эш урыны адресы (индекс белән) _________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының эш телефоны (шәһәр коды белән) __________________________________
Грантка дәгъва кылучының теркәлү адресы (индекс белән) ___________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының элемтә телефоны (мобиль, яки шәһәр коды белән шәһәр телефоны)
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының паспорт мәгълүматлары__________________________________________
________________________________________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының иминият таныклыгы номеры (СНИЛС)_____________________________
Грантка дәгъва кылучының ИНН ______________________________________________________________
Грантка дәгъва кылучының эш стажы: гомуми ____________ мәдәният өлкәсендә ________________

☐ Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза ___________ ___________________________________

(имза) (грантка дәгъва кылучының ФИАи)

Грантка дәгъва кылучы

_________________________ ___________________________________

(имза) (ФИАи)

Гариза бирүче вәкиле

_________________________ ___________________________________

(имза) (ФИАи)

МУ

Дата

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә**
**ГАРИЗА-РИЗАЛЫК**

Мин,____________________________________________________________________

*(Фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)*

түбәндәге адрес буенча яшәүче:______________________________________________

(шәхесне раслаучы документ: паспорт, серия номер ________________________________,

________________________________________________________________________

________________________________________________________________ тарафыннан бирелгән)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Пушкин ур., 66/33 нче йорт) Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алуга конкурста катнашу өчен минем тарафтан бирелгән минем шәхси мәгълүматларны (белешмәләрне), шул исәптән фамилиям, исемем, атамның исеме; туу датасы һәм урыны; җенесем; белемем; гыйльми дәрәҗәм; өстәмә һөнәри белемем; һөнәрем (белгечлегем); эш стажым; дәүләт бүләкләрем һәм башка бүләкләрем, аерым хөрмәт билгеләре булу-булмау; эшкә кабул итү, күчеп йөрү, билгеләнү һәм эштән азат ителү турында мәгълүматларым; паспорт мәгълүматларым; теркәлү һәм яшәү урыны адресым; элемтә өчен телефон номерым; дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы номерым; салым түләүченең идентификация номерым; фотография сурәтемне, автоматлаштыру чараларыннан файдаланып яисә алардан файдаланмыйча башкарыла торган эшкәртүгә (теләсә нинди гамәлгә (операциягә) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасына), шул исәптән җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алуны, куллануны, тапшыруны (тарату, бирү, күрсәтү) кертеп, ризалык бирәм.

Мин чит кеше исемен атамаска яки чит кеше исеменнән (шәхси зат яки оешма) эш йөртмәскә, белә торып дөрес булмаган мәгълүматны һәм өченче затларны идентификацияли торган яисә өченче затларга караган мәгълүматны күрсәтмәскә йөкләмә алам.

Мин түбәндәгеләр белән танышып чыктым:

1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге ризалыкны имзалау датасыннан гамәлдә була;

2) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле рәвештә язылган минем язма гаризам нигезендә кире алынырга мөмкин;

3) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән нигезләр булганда, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

4) мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте Грантын уздырганнан соң шәхси мәгълүматлар документларны саклауның законнарда каралган срогы дәвамында саклана.

Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, тулы күләмдә башкара.

______________ ________________________ / ___________________/

Дата ФИАи имза

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**Мәдәният хезмәткәре эшчәнлеге турында аналитик белешмә**

Документ түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1. Хезмәткәргә кыскача характеристика *(бу кешегә хас булган холыкны, шәхси сыйфатларны һәм һөнәри күнекмәләрне тасвирлау таләп ителә).*

2. Грантка дәгъва кылучы эшчәнлегенең төп критерийларына җавап бирә торган мәгълүмат:

Грантка дәгъва кылучының соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) конкурсларда һәм проектларда шәхси катнашуының нәтиҗәлелеге;

соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) квалификация күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерлек;

дәүләт бүләкләре (орденнар, медальләр, мактаулы исемнәр) булу;

бүләкләүләр һәм кызыксындыру чаралары (федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәләрдәге, дәүләтнеке булмаган учреждениеләрдәге мактау грамоталары, күкрәк билгеләре, рәхмәт хатлары) булу.

3. Грантка дәгъва кылучы эшчәнлегенең өстәмә критерийларына җавап бирә торган мәгълүмат:

<u>«Иң яхшы җитәкче» номинациясе буенча:</u>

соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) Учреждение эшчәнлеген федераль һәм региональ массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

соңгы 2 елда (агымдагы ел һәм Гариза бирелгән елга кадәрге ел) иҗади проектларны тормышка ашыруга һәм матди-техник базаны ныгытуга өстәмә финанс чаралары җәлеп итү;

Учреждениенең Интернет-сайты булу һәм аның яңартылуы даими алып барылу.

<u>«Профессионал» номинациясе буенча:</u>

һөнәри басма материаллар, фәнни-тикшеренү тәҗрибәсе һәм иҗади эш (вакытлы матбугатта, массакүләм мәгълүмат чараларында, җыентыкларда һ.б.ш.да мәкаләләр), брошюралар һ.б. булу;

эш процессында заманча технологияләрне, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану;

үз тәҗрибәсен муниципаль һәм (яки) региональ дәрәҗәдә гомумиләштерү һәм тарату (мастер-класслар, семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, спикер яки жюри сыйфатында).

<u>«Таяныч һәм абруй» номинациясе буенча:</u>

остазлык системасы: Учреждениедә тәрбияләнгән укучылар (эшне дәвам итүчеләр) булу;

авторлык программалары, методик һәм дидактик эшләнмәләр, тәкъдимнәр, укыту-методик әсбаплар, җыентыклар булу;

үз тәҗрибәсен муниципаль һәм (яки) региональ дәрәҗәдә гомумиләштерү һәм тарату (мастер-класслар, семинарлар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, спикер яки жюри сыйфатында).

<u>«Перспектива» номинациясе буенча»:</u>

үз проектларын/идеяләрен эшләү һәм Учреждение эшенә кертү (эшкә урнашкан вакыттан алып);

коллективның иҗтимагый тормышында һәм үткәрелә торган чараларда актив катнашу;
Учреждение җитәкчесенең уңай бәяләмәсе булу.

Аналитик белешмә Гариза бирүче вәкиле тарафыннан имзалана һәм кәгазьдә тапшырыла.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

(Форма)

| **Проект** | |
|---|---|
| Проектның кыскача эчтәлеге | *Проектның төп идеяне чагылдыра торган текст рәвешендәге презентациясе (1000 символдан күбрәк түгел)* |
| Проектның актуальлеген һәм социаль әһәмиятен нигезләү | *Сайлап алынган чара буенча укуның һәм (яки) катнашуның зарурлыгы, шулай ук үз һөнәри максатларына ирешү һәм Учреждениенең/муниципаль районның/шәһәрнең/Республиканың социаль-мәдәни үсешенә булышлык итү өчен алган белемнәрне һәм практик тәҗрибәне дәгъва кылучы тарафыннан гамәлгә ашыру нигезләнә (1000 символдан күбрәк түгел)* |
| Проектның максаты һәм бурычлары | *Максатлар гомуми терминнар белән, шул ук вакытта эшчәнлекнең төгәл бер нәтиҗәләрен билгели торган бурычлар рәвешендә языла (нәрсәгә ирешү, нәрсә алу планлаштырыла)* |
| Көтелгән нәтиҗәләр | |
| Сан ягыннан нәтиҗәләр | *Төгәл, сан күрсәткечләрендә исәпләнә торган нәтиҗәләр һәм күрсәткечләрнең план буенча зурлыклары языла* |
| Сыйфат нәтиҗәләре | *Сан күрсәткечләрендә исәпләнми торган нәтиҗәләр күрсәтелә* |
| Проектны гамәлгә ашыру сроклары | |
| Проектны гамәлгә ашыра башлау датасы | *(ай, ел)* |
| Проектны гамәлгә ашыру төгәлләнү датасы | *(ай, ел)* |

**Грантка дәгъва кылучы**

____________________ ____________________________
(имза) (ФИАи)

**Гариза бирүче вәкиле**

____________________ ____________________________
(имза) (ФИАи)

МУ

Дата

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

(Форма)

РАСЛЫЙМ

___________________________________

(Гариза бирүче вәкиле:
вазыйфасы, Ф.И.А.и.)

«____» __________, 20__ ел

М.У.

**Чыгымнар сметасы**

| Статьяның исеме | Грант акчалары | Башка финанслау чыганаклары акчалары | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| **Турыдан-туры чыгымнар** | | | |
| | | | |
| | | | |
| **Турыдан-туры чыгымнар буенча барлыгы** | | | |
| **Проект буенча башка чыгымнар** | | | |
| | | | |
| | | | |
| **Барлык башка чыгымнар** | | | |
| **Проект буенча барлык чыгымнар** | | | |

Баш хисапчы (бухгалтер) _____________ ____________________

(имза) (ФИАи)